КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 23 ноябрь г.Казань № 1045

Татарстан Республикасында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары белән кире элемтә механизмын формалаштыру һәм үстерү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларында яңа инвестиция проектларына ярдәм итү системасы турында («Төбәк инвестиция стандарты»)» 2021 елның 30 сентябрендәге 591 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасының Кире элемтә платформасы аша керә торган мөрәҗәгатьләрен карау процедурасына бердәм якын килүне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары белән кире элемтә механизмын формалаштыру һәм үстерү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы каршында Татарстан Республикасында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшче төркем төзергә һәм әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары белән кире элемтә механизмын формалаштыру һәм үстерү тәртибендә күрсәтелгән мөрәҗәгатьләр классификаторын расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 23 ноябрь, 1045 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары белән кире элемтә механизмын булдыру һәм үстерү тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларында яңа инвестиция проектларына ярдәм итү системасы турында («Төбәк инвестиция стандарты»)» 2021 елның 30 сентябрендәге 591 номерлы боерыгы белән Россия Федерациясе субъектларында инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары белән кире элемтә механизмын булдыру һәм үстерү буенча методик тәкъдимнамәләр нигезендә, Татарстан Республикасында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының (алга таба – Гариза бирүчеләр) «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасының Кире элемтә платформасы (алга таба – Кире элемтә платформасы) аша керә торган мөрәҗәгатьләрен карау процедурасына бердәм якын килүне тәэмин итү максатларында эшләнде.

1.2. Әлеге Тәртип түбәндәгеләрне билгели:

Татарстан Республикасында Гариза бирүчеләр белән кире элемтә механизмын формалаштыру һәм үстерү мәсьәләсенә караган төп төшенчәләр;

Татарстан Республикасында Гариза бирүчеләр белән кире элемтә механизмы кысаларында мөрәҗәгатьләрне эшкәртүне гамәлгә ашыручы үтәүчеләрнең гамәлләр кылу сроклары һәм эзлеклелеге;

Гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен эшкәртү бердәм үзәге (алга таба – Бердәм үзәк) эшчәнлеге регламенты;

Татарстан Республикасында кире элемтә каналлары;

Гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе һәм сроклары;

мөрәҗәгатькә алынган җавап белән Гариза бирүчеләрнең канәгать булуын ачыклау ысуллары һәм рәвешләре;

Гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре турында хисап (алга таба – хисап) формасы.

1.3. Гариза бирүчеләрдән кергән һәм әлеге Тәртип нигезендә карала торган мөрәҗәгатьләр –хәбәр, ягъни физик һәм юридик затлар өчен электрон документ рәвешендә җибәрелгән актуаль проблемаларны хәл итү кирәклеге турында мәгълүмат булып тора; карап тикшерү һәм җаваплар җибәрү өчен аңа карата федераль, төбәк, ведомство хокукый актлар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карарлары буенча «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә кагылышлы булмаган һәм, әгәр федераль законнарда яки Россия Федерациясе Хөкүмәте карары

белән башкасы каралмаган булса, 10 календарь көннән артмаган тизләтеп карау сроклары билгеләнә, ул электрон документ рәвешендә җибәрелә.

## II. Төп төшенчәләр

2.1. Бу Тәртип максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) Гариза бирүчеләр – дәүләт тарафыннан теркәлү урыны нинди булуга карамастан, инвестиция һәм (яисә) эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче теләсә нинди оештыру-хокук рәвешендәге физик затлар һәм юридик затлар;

2) Бердәм үзәк – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;

3) мөрәҗәгатьләр классификаторы – мөрәҗәгатьләрне маршрутлаштыру өчен кулланыла торган тематик категорияләр, ярдәмче категорияләр һәм фактлар системасы (алга таба – Классификатор);

4) кире элемтә каналлары – Гариза бирүчеләр эшкуарлык һәм (яисә) инвестиция эшчәнлеге алып бару барышында барлыкка килгән актуаль проблемалар, мәсьәләләр һәм тәкъдимнәр турында хәбәр итә ала торган чыганаклар;

5) координатор – Бердәм үзәкнең Гариза бирүчеләрдән карау өчен кергән мөрәҗәгатьләрне кабул итүне, модерацияләүне һәм координацияләүне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи заты;

6) кире элемтә механизмы – кире элемтә каналлары буенча алынган эшмәкәрлек һәм (яисә) инвестиция эшчәнлеге өлкәсендәге мәсьәләләр буенча мөрәҗәгатьләрне кабул итү, эшкәртү (мөрәҗәгатьне теркәү, классификатор нигезендә мөрәҗәгатьне маршрутлаштыру, мөрәҗәгатьләрне асылы буенча карау, җавапларны әзерләү срокларын һәм аларның сыйфатын контрольдә тоту) һәм ябу (Гариза бирүчегә телдән һәм (яисә) язмача җавап бирү, Гариза бирүченең канәгать булуын ачыклау), шулай ук әлеге Тәртиптә каралган тәртиптә билгеле бер вакыт өчен мөрәҗәгатьләр турында белешмәләрне анализлау эшчәнлегендә катнашучыларның үзара хезмәттәшлеген оештыру ягыннан, хокукый, мәгълүмати, коммуникацион һәм техник тәэмин итү;

7) башкаручы – компетенция чикләрендә мөрәҗәгатьләрне асылы буенча карау, аңа җавап әзерләү һәм җибәрү өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнары, башка оешмалар.

Классификатор нигезендә категорияләргә, ярдәмче категорияләргә һәм фактларга бәйле рәвештә башкаручылар исемлеге хезмәт документы булып тора һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының, башкаручылар файдалана алган һәм чикләнмәгән затлар даирәсе өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыруга каралмаган боерыгы белән раслана;

8) «консультация» буенча мөрәҗәгать – эшкуарлык һәм (яисә) инвестиция эшчәнлеге өлкәсендәге мәсьәләләр буенча Гариза бирүчедән алынган документларны өйрәнүне яисә өстәмә мәгълүматны таләп итми торган мөрәҗәгать (алга таба – «консультация»), аны карап тикшерү нәтиҗәсе – Гариза бирүчегә телдән һәм (яисә) электрон формада аңлатмалар бирү;

9) «проблема» буенча мөрәҗәгать – эчтәлегеннән күренгәнчә, Гариза бирүченең эшкуарлык һәм (яисә) инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозыла яисә бозылачак турында мөрәҗәгать (алга таба – «проблема»).

10) «ярдәм» буенча мөрәҗәгать – башкаручы тарафыннан хәл итү өчен кирәкле

гамәлләр кылуны таләп итә торган эшкуарлык һәм (яисә) инвестиция эшчәнлеге өлкәсендәге мәсьәләләр буенча, шул исәптән Гариза бирүче тапшырган документларны өйрәнү һәм (яки) Гариза бирүченең мәсьәләсен хәл итү максатларында хакимият органнарына һәм оешмаларга рәсми сораулар җибәрү буенча мөрәҗәгать («проблема» буенча мөрәҗәгатьтән тыш) (алга таба – «ярдәм»);

11) системалы сорау – хәл итү барышында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив хокукый акты кабул ителә яисә аңа үзгәреш кертелә, хокук куллану практикасы үзгәртелә, аларны хәл итү ысуллары турында мәгълүмат таратыла алган, эчтәлеге һәм тематикасы буенча охшаш булган мөрәҗәгатьләр җыелмасы.

## III. Бердәм үзәк эшчәнлеге регламенты

3.1. Бердәм үзәк түбәндәге функцияләрне башкара:

мөрәҗәгатьләр кабул итү, шулай ук кирәк булганда башкаручыларга аларның маршрутын төзү һәм (яисә) карау;

әлеге Тәртиптә билгеләнгән башкаручылар тарафыннан мөрәҗәгатьләргә җаваплар әзерләү сроклары үтәлешен контрольдә тоту;

системалы мәсьәләләрне ачыклау;

Гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатькә бирелгән җаваптан канәгатьлеген ачыклау, канәгатьлелекне түбән бәяләү алган һәм (яисә) Гариза бирүчеләрдән кабат карауга кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау, шул исәптән системалы проблемаларны ачыклау һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы каршындагы Гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшче төркем (алга таба – Эшче төркем) утырышларында карау максатларында;

классификаторны актуальләштерү буенча мотивлаштырылган тәкъдимнәрне формалаштыру;

карап тикшерелгән мөрәҗәгатьләр турында мәгълүматны анализлау һәм Кире элемтә платформасыннан алынган мөрәҗәгатьләр турында мәгълүматны күчереп алу юлы белән хисаплар әзерләү.

3.2. Бердәм үзәк җитәкчесе - Татарстан Республикасы икътисад министрының инвестиция блогын җитәкли торган урынбасары (алга таба – Бердәм үзәк җитәкчесе).

3.3. Бердәм үзәк җитәкчесе:

Бердәм үзәк эшчәнлегенең гомуми координациясен даими нигездә тәэмин итә;

әлеге Тәртиптә каралган функцияләрне башкару буенча Бердәм үзәкнең көндәлек операцион эшчәнлеген тәэмин итә;

Бердәм үзәк кураторына һәм әлеге Тәртиптә каралган башка затларга Бердәм үзәк эшчәнлеге юнәлешләре буенча, шул исәптән ачыкланган системалы мәсьәләләр турында аналитик һәм мәгълүмати материалларны тәкъдим итә;

Бердәм үзәк функцияләрен үтәү өчен шәхсән җавап бирә.

3.4. Бердәм үзәк кураторы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры (алга таба – Бердәм үзәк кураторы).

3.5. Бердәм үзәк кураторы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

Татарстан Республикасында кире элемтә механизмын гамәлгә ашыруны

тикшереп тору;

Бердәм үзәк эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү.

3.6. Бердәм үзәк эшчәнлеген финанс һәм оештыру-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчасы чикләрендә гамәлгә ашырыла.

## IV. Татарстан Республикасында кире элемтә каналлары

4.1. Татарстан Республикасында Гариза бирүче өчен кире элемтә каналлары:

1) Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы;

2) «Татарстан Республикасы инвестиция порталы» мәгълүмат ресурсы;

3) «Россия Федерациясе инвестиция картасы» мәгълүмат ресурсы.

## V. Эшче төркем

5.1. Эшче төркем Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы нигезендә төзелә.

5.2. Эш төркеме түбәндәгеләрне карап тикшерә:

кабат карау нәтиҗәләре буенча Гариза бирүчедән канәгатьләнерлек булмаган билгесе булган «консультация» һәм «ярдәм» буенча мөрәҗәгатьләрне;

«проблемалар» буенча мөрәҗәгатьләрне;

системалы мәсьәләләрне;

мондый мөрәҗәгатьләрнең тематикасын күрсәтеп, мөрәҗәгатькә бирелгән җаваплар белән канәгатьлелек түбән булу сәбәпләре.

5.3. Эшче төркем рәисе – Бердәм үзәк кураторы. Эшче төркем секретаре – Бердәм үзәк җитәкчесе.

5.4. Эшче төркем утырышлары кирәк саен турыдан-туры яки турыдан-туры һәм читтән торып, шул исәптән видеоконференция элемтәсе форматында, әмма аена бер тапкыр уздырыла.

5.5. Бердәм үзәк җитәкчесе мөрәҗәгать кергән көннән алып бер эш көне эчендә Эшче төркем рәисенә Эшче төркем утырышын уздыру кирәклеге турында мәгълүмат җиткерә.

Эшче төркеме утырышы Эшче төркем утырышын уздыру кирәклеге турында мәгълүмат җиткерелгән көннән алып 14 календарь көннән дә соңга калмыйча уздырыла.

5.6. Эшче төркем рәисе Эш төркем утырышының көн тәртибендәге мәсьәләләрдән чыгып, утырышта катнашучылар исемлеген билгеләргә хокуклы.

5.7. Эшче төркемгә, мөрәҗәгатьләрне карау эшчәнлегеннән тыш, хисапны расларга һәм аны Эшче төркем эшчәнлеге турында доклад белән бергә Татарстан Республикасы Рәисенә ай саен кертү өчен җибәрергә тәкъдим ителә.

## VI. «Консультацияләр» һәм «ярдәм» буенча мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү тәртибе һәм сроклары

6.1. «Консультацияләр» буенча мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү срогы –

5 календарь көнгә кадәр, «ярдәм» буенча мөрәҗәгатьләрне 10 календарь көнгә кадәр (федераль закон яисә башка норматив хокукый актлар белән каралган башка сроклардан тыш).

6.2. Башкаручы Кире элемтә платформасыннан мөрәҗәгать кергән көннән түбәндәгеләрне башкарырга кирәк:

«консультацияләр» буенча мөрәҗәгатьләр кергәндә, аның мәсьәләсе буенча телдән аңлатмалар бирү өчен Гариза бирүче белән элемтәгә керергә, телдән аңлатмалар бирү мөмкинлеге булмаганда, җавапны язма рәвештә бирергә;

«ярдәм» буенча мөрәҗәгатьләр кергәндә, «ярдәм» мәсьәләсенә караган өстәмә материаллар алу өчен Гариза бирүче белән элемтәгә керергә, шулай ук Татарстан Республикасында хакимият органнарыннан һәм оешмалардан кирәкле белешмәләр алырга, язма (электрон) рәвештә җавап әзерләргә һәм аны Гариза бирүчегә Кире элемтә платформасы аша җибәрергә.

6.3. Башкаручыга «консультацияләр» һәм «ярдәм» буенча карап тикшерелгән мөрәҗәгатьләрнең нәтиҗәләре буенча мәгълүматларны Кире элемтә платформасына кертергә кирәк.

Телдән аңлатмалар биргәндә Кире элемтә платформасында тиешле тамга куярга, Гариза бирүче өчен комментариядә яки җавап текстында үткәрелгән консультация нәтиҗәләре турында күрсәтергә кирәк.

Гариза бирүчедән «кайнар» линиягә яисә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә кергән мөрәҗәгатьләр, «Мөрәҗәгатьләрне кабул итү операторы» функционалын кулланып, Кире элемтә платформасында теркәлергә һәм эшкәртелергә мөмкин.

6.4. «Консультация» яисә «ярдәм» мәсьәләсе буенча аңлатмалар бирү йомгаклары буенча Бердәм үзәккә, Гариза бирүчедән «консультация» яисә «ярдәм» предметы буенча бирелгән аңлатмалардан канәгатьлек турында фикер алу максатларында, аңа рәсми сорау җибәрергә һәм Гариза бирүчедән алынган мәгълүматны (алга таба – аңлатмалар белән канәгатьлек) Кире элемтә платформасына кертергә кирәк.

6.5. Кире элемтә платформасында аңлатмалар белән канәгатьлек «1»дән алып «5»кә кадәр биш баллы шкала буенча билгеләнә.

6.6. Әгәр Кире элемтә платформасында мөрәҗәгатькә җавап өчен Гариза бирүчедән «1», «2» яисә «3»гә тигез билге алынса, Бердәм үзәккә канәгатьлек түбән булу сәбәпләренә анализ ясарга кирәк.

6.7. Гариза бирүче Кире элемтә платформасында кабат карауга мөрәҗәгатьне кире кайтарырга хокуклы. Мөрәҗәгать кабат карауга кире кайтарылганда, Кире элемтә платформасында аны һәрьяклап һәм вакытында карауны тәэмин итәргә кирәк.

6.8. Әгәр мөрәҗәгать билгеләнгән вакытта каралмаса, Кире элемтә платформасында җавап әзерләгәндә «Кичектерелде» дигән җавап төрен мәҗбүри тәртиптә кулланырга кирәк.

«Кичектерелде» дигән җавап төрен кулланганда, башкаручыга мөрәҗәгать карау кичектерелә торган датаны күрсәтергә кирәк. Мөрәҗәгатьне карау кичектерелергә мөмкин булган срок 30 календарь көнгә кадәр тәшкил итә.

6.9. Гариза бирүче аңлатмалар белән канәгать булса, «консультация» яисә «ярдәм» буенча мөрәҗәгать ябылган дип санала.

Гариза бирүче аңлатмалар белән канәгатьләнмәгән һәм мөрәҗәгатьне әлеге

мәсьәлә буенча кабат карау (эшләп бетерү) өчен кире кайтарган очракта, мөрәҗәгатьне кабат карау Бердәм үзәк тарафыннан гамәлгә ашырыла һәм кирәк булганда башкаручы җәлеп ителә.

6.10. Әгәр мөрәҗәгать буенча канәгатьләнерлек булмаган бәя бирелмәгән яисә мөрәҗәгать Кире элемтә платформасына кабат карау өчен кире кайтарылмаган булса, «консультация» яисә «ярдәм» буенча мөрәҗәгать ябылган дип санала.

6.11. «Консультация» һәм «ярдәм» буенча башка мөрәҗәгатьләргә карата түбәндәге «консультация» һәм «ярдәм» буенча мөрәҗәгатьләрне өстенлекле тәртиптә карарга кирәк:

кабат карауга кергән;

Татарстан Республикасы территориясендә Татарстан Республикасы Президентының «2028 елга кадәр Татарстан Республикасы Инвестиция декларациясе турында» 2012 елның 18 июнендәге ПУ-477 номерлы Указы белән расланган 2028 елга кадәр Татарстан Республикасы Инвестиция декларациясендә билгеләнгән икътисадның өстенлекле тармакларында инвестиция проектын гамәлгә ашыручы яисә гамәлгә ашыруны планлаштыручы Гариза бирүчеләрдән кергән;

Гариза бирүчеләрнең бөлгенлеккә төшү (банкрот булу) һәм (яисә) аларның эшчәнлеген киләчәктә туктатылу мөмкинлеге белән бәйле мәсьәләләр буенча.

6.12. Әгәр Гариза бирүче «консультацияләр» яисә «ярдәм» буенча мөрәҗәгатьләрне кабат карау йомгаклары буенча бирелгән аңлатмалар белән канәгатьләнмәгән булса, мәсьәлә Эш четөркем утырышында карала.

## VII. «Проблемалар» буенча мөрәҗәгатьләрне һәм системалы мәсьәләләрне карау

7.1. Эшче төркем утырышын әзерләгәндә Эшче төркем секретаре:

Эшче төркем утырышын әзерләү эшен оештыра;

Эшче төркем утырышының көн тәртибен әзерли, Эшче төркем рәисе белән килештереп, Эшче төркем утырышына чакырылган затлар исемлеген төзи;

Эшче төркем утырышында каралырга тиешле мәсьәләләр буенча материаллар җыя һәм әзерли;

Эшче төркем утырышы беркетмәсен (алга таба – беркетмә) алып бара;

Беркетмә өземтәсен Гариза бирүчегә, Эшче төркем әгъзаларына, Эшче төркем утырышына чакырылган башка затларга җибәрә;

Эшче төркем утырышында мөрәҗәгатьләрне һәм системалы мәсьәләләрне карау йомгаклары турында мәгълүматны Кире элемтә платформасына кертә.

7.2. Гариза бирүче үз мәсьәләсе буенча фикер алышу өчен Эшче төркем утырышында (Эшче төркем рәисе утырышны Гариза бирүчедән башка уздыру турында карар кабул иткән очрактан тыш) катнаша.

7.3. Эшче төркем карары беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

7.4. Беркетмә Эшче төркем рәисе тарафыннан Эшче төркем утырышы үткәрелгән көннән 5 календарь көн эчендә раслана.

7.5. Координатор беркетмә расланган көннән алып 2 календарь көн эчендә Гариза бирүчегә беркетмәдән өземтә җибәрә.

7.6. Әгәр Гариза бирүче үз мөрәҗәгате буенча Эшче төркем карары (алга таба –

мөрәҗәгать буенча карар) белән канәгать булса, мөрәҗәгать ябылган дип саналырга мөмкин.

Әгәр Гариза бирүче тарафыннан мөрәҗәгать буенча карар турында карашы беркәтмә өземтәсен теркәп җавап җибәрелгән вакыттан алып 30 календарь көн эчендә белдерелмәсә, мөрәҗәгать ябылган дип санала.

Гариза бирүче, мөрәҗәгать буенча карар белән килешмәгән очракта, Эшче төркемгә мөрәҗәгать җибәрергә хокуклы.

7.7. Мөрәҗәгать буенча карар турында мәгълүмат Кире элемтә платформасына кертелә һәм Гариза бирүчегә җибәрелә.

Гариза бирүче тарафыннан мөрәҗәгать өчен бирелгән җавапларга куелган билгеләр турында мәгълүмат Кире элемтә платформасында автомат рәвештә формалаштырыла.

## VIII. Хисап формасы һәм кире элемтә механизмының нәтиҗәлелеген бәяләү

8.1. Татарстан Республикасында кире элемтә механизмын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү максатларында Бердәм үзәк базасында Бердәм үзәк җитәкчесе тарафыннан әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча атналык хисап төзелә.

8.2. Бердәм үзәк җитәкчесе атна саен Бердәм үзәк кураторына хисап җибәрә.

8.3. Хисап әзерләү өчен мәгълүмат чыганагы булып Бердәм үзәк мәгълүматлары тора.

8.4. Хисапта «консультацияләр», «ярдәм» и «проблемалар» турында мәгълүмат чагылдырыла, шулай ук аңа түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

кире элемтә каналлары киселешендә хисап чоры өчен мөрәҗәгатьләр саны;

башкаручылар киселешендә хисап чоры өчен мөрәҗәгатьләр саны;

хисап төзү датасына мөрәҗәгатькә җаваплар саны;

хисап төзегән датага эштәге мөрәҗәгатьләр саны;

эшләп бетерүгә юнәлдерелгән мөрәҗәгатьләр саны, шулай ук хисап төзү датасына карата мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан аларның өлеше;

ачыкланган һәм хәл ителгән системалы мәсьәләләр саны һәм аларның эчтәлеге;

карау срогы тәмамланган мөрәҗәгатьләр саны (мөрәҗәгатьнең вакытында каралмау сәбәбен күрсәтеп);

хисап чоры өчен ябылган мөрәҗәгатьләр саны (беренчел һәм кабат кергән мөрәҗәгатьләр);

узган хисап чоры белән чагыштырганда, хисап чорында мөрәҗәгатьләр саны буенча динамика;

Гариза бирүчеләр тарафыннан аеруча таләп ителә торган мөрәҗәгатьләр.

Татарстан Республикасында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары белән кире элемтә механизмын формалаштыру һәм үстерү тәртибенә кушымта

Форма

___________ алып ________________ га кадәрге чор өчен гариза бирүчеләр мөрәҗәгатьләре турында хисап

| Күрсәткече | Барлыгы | «Консультация» буена мөрәҗәгать | «Ярдәм» буенча мөрәҗәгать | «Проблема» буенча мөрәҗәгать |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Хисап чоры өчен кире элемтә каналлары киселешендә мөрәҗәгатьләр саны | | | | |
| Хисап чоры өчен мөрәҗәгать буенча башкаручылар киселешендә мөрәҗәгать саны | | | | |
| Хисап төзү датасына мөрәҗәгатькә бирелгән җаваплар саны | | | | |
| Хисап төзү датасына эштәге мөрәҗәгатьләр саны | | | | |
| Эшләп бетерүгә юнәлдерелгән мөрәҗәгатьләр саны, шулай ук хисап төзү датасына карата мөрәҗәгатьләрнең гомуми санынннан аларның өлеше | | | | |
| Ачыкланган һәм хәл ителгән системалы мәсьәләләр саны һәм аларның эчтәлеге | | | | |
| Карау срогы тәмамланган мөрәҗәгатьләр саны (мөрәҗәгатьнең вакытында каралмау сәбәбен күрсәтеп) | | | | |
| Хисап чоры өчен ябылган мөрәҗәгатьләр саны (беренчел һәм кабат кергән мөрәҗәгатьләр); | | | | |
| Узган хисап чоры белән чагыштырганда, хисап чорында | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| мөрәҗәгатьләр саны буенча динамика | | | | |
| Гариза бирүчеләр тарафыннан аеруча таләп ителә торган мөрәҗәгатьләр | | | | |

Хисап төзү датасы:

Гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен эшкәртү бердәм үзәге җитәкчесе _____________

________________________________________